# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең Надеждино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**26 ноябрь , 2024 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 25 ноябренә 11 сәгатьтә, 2024 елның 25 ноябренә 14 сәгатьтә, 2024 елның 26 ноябренә 10 сәгатьтә, этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 120 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -65, бу 54.2 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 65 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең Надеждино торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ

булган һәр яшәүчедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме

- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Надеждино авыл җирлеге Башлыгы Е.В.Савельева